# Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы

## КАРАР

12 ноябрь, 2020ел. № 7

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 ел, 23 ноябрь, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Яңа Ибрай авылы Совет урамы, 6 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасы янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең Яңа Ибрай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 23 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Яңа Ибрай авылы, Совет урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең Яңа Ибрай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2020 елның 23 ноябрендә 16.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Яңа Ибрай авылы, Совет урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең Яңа Ибрай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген 3 өлешкә бүләргә:
5. 1) Революция ур., Нагорная ур., Сөлчә ур.;
6. 2) Ленин ур., Комсомол ур., Карл Маркс ур., Пионер ур., Завод ур., Пушкин ур., Чапай ур.
7. 3) Г.Тукай ур., Тельман ур., Совет ур., Октябрь ур., Гагарин ур., Бауман ур., Вахитов ур.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, беренче төркем инвалидлардан, сугыш ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1. җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:

- кышкы юлларны карап тоту.

- Яна Ибрай авылы юлларына вак таш сатып алу һәм түшәү.
– Яңа Ибрай авылы эчендәге юлларны тигезләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда белдерү такталары һәм стендларда урнаштыру юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл
җирлеге башлыгы: Ф. Х. Кәбиров